Республика Татарстан
Зеленодольский муниципальный район
**Исполнительный комитет Новопольского сельского поселения**
Свободы ул, 39 п.Новопольский,
тел/факс:3-59-47
E-mail: Npol.Zel@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Зеленодол муниципаль районы
**Новополька авыл җирлеге башкарма комитеты**
Иреклек ур., 39 Новополька п,
тел/факс:3-59-47
E-mail: Npol.Zel@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**КАРАР**

« 14 »  июне  2019 елның №55

Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районының Новополька авыл җирлеге генераль планы проектына үзгәрешләр кертүгә әзерлек комиссиясе Нигезләмәсен раслау турында

Россия Федерациясенең 2004 елның 29 декабрендәге 190-ФЗ номерлы Шәһәр төзелеше кодексының 8 һәм 24 статьялары, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районының Новополька авыл җирлеге Уставы нигезендә, Новополька авыл җирлеге Генераль планын әзерләү һәм раслауны тәэмин итү максатларында

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Новополька авыл җирлеге генераль планы  проектына үзгәрешләр кертүгә әзерлек комиссиясе турында Нигезләмәне  расларга (1нче кушымта).
2. Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районының Новополька авыл җирлеге генераль планы  проектына үзгәрешләр кертүгә әзерлек комиссиясе составын расларга (2нче кушымта)
3. 10 көн вакыт эчендә әлеге карарны Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районның Новополька авыл җирлеге Уставы билгеләгән тәртип нигезендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы (составында Зеленодол муниципаль районы сайтында http://zelenodolsk.tatarstan.ru)  урнаштырырга.
4. Әлеге карар аңа кул куелган көннән үз көченә керә, дип билгеләргә.
5. Әлеге карарны үтәүгә контрольне үземә калдырам.

Новополька авыл
җирлеге башлыгы Н.Ю.Якупов

Новополька авыл җирлеге башкарма
комитетының 2019 елның 14 июнендәге 55
номерлы карарына
1нче кушымта

**Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районының Новополька авыл җирлеге генераль планы проектына үзгәрешләр кертүгә әзерлек комиссиясе турында**

**НИГЕЗЛӘМӘ**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

Новополька авыл җирлеге генераль планы проектына үзгәрешләр кертүгә әзерлек комиссиясе генераль план проектын әзерләү һәм раслау максатларында булдырылды һәм генераль план проектын әзерләү, кирәкле мәгълүмат белән тәэмин итү һәм аны тикшерү буенча эшләр башкаруны координацияләү һәм аларның эзлеклелеген тәэмин итүче, әлеге эшләрне өйрәнеп башкаручылар белән үзара хезмәттәшлекне һәм тиешле проект карарларын килештерүне оештыручы коллегиаль орган буларак төзелә.

Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерация Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районнының Новополька авыл җирлеге Уставына, әлеге Нигезләмәгә таяна.

Комиссия рәистән, Комиссия әгъзаларыннан һәм секретарьдан гыйбарәт.

Комиссия рәисен Новополька авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе билгеләп куя.

Комиссия әгъзалары Новополька авыл җирлеге башкарма комитеты, Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары структур бүлекчәләре җитәкчеләре, челтәр оешмалары, җәмәгать оешмалары вәкилләре һәм җирлектә яшәүчеләр була ала.

Комиссия эшчәнлегенең төп формасы булып утырышлар һәм Комиссия рәисе кушуы буенча Комиссия әгъзалары эше тора.

Комиссия составы Новополька авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан раслана.

## 2. Комиссиянең функцияләре һәм бурычлары

2.1. Новополька авыл җирлеге генераль планы проектын әзерләү буенча эшләр башкару план-графигында каралган чаралар һәм эшләрне үз вакытында үтәүне тәэмин итү;

2.2. Новополька авыл җирлеге генераль планы проектын әзерләү һәм финанслау процессында гамәлләрне координацияләүне һәм оештыру эшен тәэмин итү;

2.3. Новополька авыл җирлеге генераль планы проектын өйрәнеп эшләүче белән үзара хезмәттәшлекне тормышка ашыру, проектны әзерләү өчен кирәк булган белешмәләр һәм материаллар алуда аларга ярдәм итү;

2.4. Новополька авыл җирлеге генераль план проектын әзерләү процессында оештыру-техник булышлык;

2.5. Новополька авыл җирлеге генераль план проекты буенча кызыксынган затларның тәкъдимнәрен физик һәм юридик затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен саклауны, шул исәптән капиталь төзелеш, муниципаль берәмлек җир кишәрлекләре һәм объектлары хокуклы биләүчеләре мәнфәгатьләрен саклауны тәэмин итү максатларында үз компетенцияләре чикләрендә карау;

2.6. Новополька авыл җирлеге генераль план проектын әзерләү өчен башлангыч белешмәләрне җыюны оештыру: генераль план проектын эшләү өчен кирәкле мәгълүматны юл картасында күрсәтелгән вакытларда, шулай ук, кирәк булганда, проектны әзерләүнең бөтен чорында әзерләүдә һәм заказчыга тапшыруда ярдәм күрсәтү;

2.7. төп юнәлешләрне һәм җирлек үсешенең вариантларын тикшерүне һәм оптималь вариант-концепцияне сайлап алуны оештыру;

2.8. проект концепциясен һәм аналитик докладны карау һәм тикшерүне, аны Новополька авыл җирлеге башкарма комитеты структур бүлекчәләре белән килештерүне оештыру;

2.9. проектның бүлекләрен алдан карауны оештыру, шулай ук проектны килештерүне оештыру;

2.10. Новополька авыл җирлеге генераль план проекты эчтәлеге турында күргәзмәләр, экспозицияләр үткәрүне, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында чыгышлар ясауны оештыру;

2.11. Комиссиянең җирлек предприятиеләре һәм җәмәгать оешмалары белән эшләвен оештыру.

### 3. Комиссиянең хокуклары

3.1. Комиссия компетенциясе нигезендә Комиссия эше һәм проекты эшләүчеләр өчен кирәк булган мәгълүматны, документлар һәм материалларны билгеләнгән тәртиптә территориаль органнардан, дәүләт хакимиятенең федераль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан соратып алырга;

3.2. Башкарма комитетның структур бүлекчәләре, муниципаль учреждениеләр һәм предприятиеләр җитәкчеләреннән Комиссия вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен кирәк булган мәгълүматны соратып алырга, шулай ук аларның белешмәләр базасыннан файдаланырга;

3.3. Новополька авыл җирлеге генераль план проектын әзерләү мәсьәләләре буенча тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне кабул итәргә һәм кире кагырга;

3.4. Комиссия утырышларында каралучы йә аның компетенциясенә керүче мәсьәләләр буенча кызыксынган органнарның, оешмаларның һәм затларның вәкилләрен чакырырга һәм мәгълүматларын, хисапларын, тәкъдимнәрен тыңларга;

3.5. билгеләнгән тәртиптә эш төркемнәре төзергә, Комиссия эшендә катнашуга экспертлар, консультантлар җәлеп итәргә;

3.6. тиешле тәкъдимнәр һәм бәяләмәләр әзерләү эшенә бәйсез экспертлар җәлеп итәргә;

3.7. үз эшчәнлеге турында материаллар бастырырга.

### 4. Комиссия эше тәртибе

4.1. Комиссия үз эшчәнлеген утырышлар формасында һәм Комиссия әгъзаларының Комиссия рәисе кушуы буенча аның әгъзаларының түләүсез нигездә шәхси катнашуы нигезендә тормышка ашыра;

4.2. Комиссия эше аның исемлек составыннан кимендә яртысы утырышларда катнашканда вәкаләтле булып тора;

4.3. Комиссия эшенең даимилиге план проектын әзерләү һәм һәм килештерү вакытларын саклау таләпләреннән чыгып, Комиссия рәисе тарафыннан билгеләнә;

4.4. Комиссия утырышын аның рәисе яисә секретаре алып бара;

4.5. Комиссия утырышларына әзерлекне аның секретариаты тәэмин итә;

4.6. Комиссия әгьзалары йә бу вазыйфаларны башкаручы затлар Комиссия утырышларында шәхсән катнаша;

4.7. Комиссия каралучы мәсьәләләр буенча карарларны утырышта катнашучылар санынннан гади күпчелек тавыш белән кабул итә. Тавышлар саны тигез булган очракта утырышта рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була;

4.8. Һәр утырыш йомгаклары Комиссия рәисе кул куйган беркетмә белән рәсмиләштерелә;

4.9. Комиссия утырышларында каралучы мәсьәләләр белән кызыксынучы оешма вәкилләре, Новополька авыл җирлеге Советы депутатлары, шулай ук Комиссия әгъзасы булмаган һәм тавыш бирү хокукына ия түгел белгечләр, җәмәгать вәкилләре, экспертлар, галимнәр, массакүләм мәгълүмат чаралары һәм башка затлар катнаша ала.

### 5. Комиссия эшчәнлеген оештыру һәм тәэмин итү

5.1. Комиссия эшчәнлегенә аның рәисе, ә ул булмаганда Комиссия секретаре җитәкчелек итә.

Комиссия рәисе Комиссия эшен җитәкли һәм координацияли, Комиссия утырышын алып бара, утырыш беркәтмәләренә кул куя, Комиссия әгъзалары арасында вазыйфаларны бүлә, утырышларда каралырга планлаштырылучы мәсьәләләр исемлеген килештерә, шулай ук Комиссия әгъзаларына документлар, материаллар әзерләү өчен бурычлар куя, аерым эшләрне йөкли, чираттагы утырышлар вакытын һәм көнен билгели, көн тәртибен раслый.

5.2. Комиссия әгъзаларының бурычлары:

5.2.1. Комиссия утырышларында каралучы мәсьәләләрне тикшерүдә шәхсән катнаша;

5.2.2. Комиссия әгъзасына йөкләнгән бүлекчәдә булган кирәкле мәгълүматны бирүне тәэмин итә;

5.2.3. Комиссия рәисе кушканнарны үз вакытында үти.

5.3. Комиссия әгъзаларының хокуклары:

5.3.1. Каралучы материалларга кагылышлы мәсьәләләргә электрон почта аша секретариатка тиешле материаллар һәм дәлилләрне кушып, искәрмәләр, тәкъдимнәр һәм өстәмәләр кертергә;

5.3.2. Комиссия эшчәнлеге мәсьәләләре буенча язмача яки телдән тәкъдимнәр кертергә;

5.3.3. дәүләт хакимияте органнарыннан, Россия Федерациясе субъектларыннан һәм башка орган һәм оешмаларыннан Новополька авыл җирлеге генераль план проектын әзерләү өчен билгеләнгән тәртиптә мәгълүмат, документлар һәм Комиссия компетенциясендәге башка материаллар соратып алырга;

5.3.4. Муниципаль учреждениеләр һәм предприятиеләрдән Комиссия вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен кирәкле мәгълүматны соратып алырга, әлеге оешмалар белешмәләре базасыннан файдаланырга;

5.3.5. Комиссия утырышларында каралучы яисә Комиссия компентенциясенә кергән мәсьәләләр буенча Комиссия утырышларында катнашу өчен кызыксынган органнар һәм оешмалар вәкилләрен катнаштыруны, алар мәгълүматын, хисабын, мөрәҗәгатен тыңлауны тәкъдим итәргә;

5.3.6. билгеләнгән тәртиптә эш төркемнәре төзүдә катнашырга. Комиссия эшендә катнашу һәм тиешле тәкъдимнәр һәм бәяләмәләр әзерләү өчен бәйсез экспертлар, консультантлар кандидатлары тәкъдим итәргә тиешле тәкъдимнәр һәм бәяләмәләр әзерләргә.

5.4. Комиссия секретариаты бурычлары:

5.4.1. Комиссия утырышларын әзерләүне тәэмин итәргә;

5.4.2. проект әзерләү барышанда кергән тәкъдимнәр нигезендә Комиссия утырышлары көн тәртибен формалаштырырга, аларны Комиссия утырышы уздыруның планлаштырылучы вакытына кадәр кимендә биш көн алдан Комиссия рәисенә раслауга бирергә;

5.4.3. барлык Комиссия әгъзаларына электрон почта аша кимендә ике көн алдан утырышның вакытын һәм көн тәртибен, тиешле материалларны җиткерергә;

5.4.4. кызыксынган затларның язмача тәкъдимнәрен кабул итәргә;

5.4.5. Комиссия утырышы беркетмәсен алып барырга, рәсмиләштерергә һәм өч эш көне дәвамында Комиссия рәисенә раслауга тапшырырга;

5.4.6. Комиссия әгъзалары искәрмәләрен, тәкъдимнәрен гомумиләштерергә һәм Комиссия рәисенә бирергә;

5.4.7. расланган беркетмәне электрон почта аша бер эш көне дәвамында Комиссия әгъзаларына җибәрергә.

Новополька авыл
җирлеге башлыгы Н.Ю.Якупов

Новополька авыл җирлеге башкарма
комитетының 2019 елның 14 июнендәге 55
номерлы карарына 2нче кушымта

Новополька авыл җирлеге генераль планы проектын әзерләү комиссиясе

**составы**

1. Комиссия рәисе – Якупов Н.Ю. Новополька авыл җирлеге башкарма комитеты башлыгы;
2. Комиссия секретаре – Нестеренко А.В. Новополька авыл җирлеге башкарма комитеты әйдәүче белгече;
3. Комиссия әгъзасы – Благодарова Т.В. Новополька авыл җирлеге 6 номерлы сайлау округы депутаты. 36нче филиал китапханәчесе;
4. Комиссия әгъзасы – Масленников С.С. Новополька авыл җирлеге 7 номерлы сайлау округы депутаты;
5. Комиссия әгъзасы – Карлаш Х.Б. Новополька авыл җирлеге 1 номерлы сайлау округы депутаты;
6. Комиссия әгъзасы – Перминов Е.М. Новополька авыл җирлеге 2 номерлы сайлау округы депутаты;
7. Комиссия әгъзасы – Сабиров Р.Р. Новополька авыл җирлеге 3 номерлы сайлау округы депутаты.